**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

22.05.2023 № 624-п

Татарстан Республикасы территориясендә Омшы, Евлевка, Бота, Писмән, Бөгелмә, Соколка, Брустан, Ашбула, Айтуган, Зөбәй, Криуша, Болгар, Нократ елгалары су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасының Түбән Кама, Тукай, Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә муниципаль районнары территориясендә урнашкан Ошмы елгасының, Евлевка елгасының, Бота елгасының, Писмән елгасының, Бөгелмә елгасының, Соколка елгасының, Брустан елгасының, Ашбуга елгасының яр буе линияләренең (су объектлары чикләренең), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү» 2022 елның 22 апрелендәге 22МЭ-3ф номерлы, «Татарстан Республикасы Сарман, Тукай, Алабуга, Әлмәт, Бөгелмә муниципаль районнары территориясендә урнашкан Айтуган елгасының, Зөбәй елгасының, Криуша елгасының, Болгар елгасының, Кече Шилнә авыл җирлегендәге 2 исемсез күлнең яр буе линияләренең (су объектлары чикләренең), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү» 2022 елның 26 августындагы 22МЭ-5ф номерлы дәүләт контрактлары буенча башкарылган эшләрнең, шулай ук Кукмара районының Лубян авылы районында чыганактан 1251,90 – 1257,56 км аралыкта сул як яры буенча Нократ елгасының яр буе линиясе урнашкан урынны (су объекты чикләрен) билгеләү эшләре нәтиҗәләре нигезендә, дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары чикләре турында белешмәләр кертү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык сызыклары киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр

эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Омшы елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.2. Евлевка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.3. Бота елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.4. Писмән елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.5. Бөгелмә елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.6. Соколка елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.7. Брустан елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 градустан азрак булганда – 40 м.

1.8. Ашбуга елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.9. Айтуган елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.10. Зөбәй елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.11. Криуша елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 50 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 50 м.

1.12. Болгар елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градустан күбрәк булганда – 50 м.

1.13. Нократ елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов) су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурслары федераль агентлыгына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органнарына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В. Веселова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (Е.К.Вахитова) әлеге боерыкны, теркәтү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.В.Манидичевага йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков